РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» апрель 2021 ел г. Альметьевск № 514

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 ноябрендәге 999 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 02 октябрендәге 3737 номерлы, 2013 елның 04 октябрендәге 3757 номерлы, 2014 елның 14 мартындагы 726 номерлы, 2015 елның 9 ноябрендәге 1290 номерлы, 2016 елның 31 маендагы 1147 номерлы, 5 февраль 2018 елның 11 сентябрендәге 1655 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге 166 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның икенче абзацындагы 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм караган өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенең өстәмә компенсация билгеләгәндә гаилә әгъзаларының соңгы 12 календарь айда керемнәре суммасыннан чыгып, җан башына уртача керемле гаиләләргә 20,0 мең сумга кадәр, гаилә әгъзаларының билгеләнеше турында гариза бирү ае алдыннан алты календарь ай алдыннан алдагы айдагы керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга,

Зак. № 305-2000

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы — А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ